**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423737, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75 а йорты

**СОВЕТ АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423737, село Атясево, ул. Центральная, д. 75 а

**КАРАР**
**«20» ноябрь 2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 10**

Әтәс авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 7 августындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Әтәс авыл җирлеге территориясендә 2021 елда бер тапкыр түләнә торган салымның 18 яшькә җиткән, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәткә бәйсез рәвештә, 2021 елда бер тапкыр түләү кертүгә сез, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 1 теркем инвалидлардан (аларның саны җирлек халкының гомуми саныннан 30 проценттан да артмый), җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 500 (биш йөз) сум күләмендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:

1. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
2. Урамнарны яктырту җайланмаларын карап тоту.
3. Юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)
4. Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру.
5. Һәйкәлләрне яшелләндерү һәм төзекләндерү, обелиск төзү.
6. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: вак авыл хуҗалыгы техникасы һәм инструментлары сатып алу.

2. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Әтәс авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтәс авыл җирлеге башлыгы: Э.Ф.Насыйрова